Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Бишмунча авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

1 ноябрь 2019 ел N 3

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Бишмунча авыл җирлегенең
Кама-Елга вылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең Кама-Елга авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын 2019 елның 16 ноябрендә 17 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Бишмунча авыл җирлегенең Кама-Елга авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Кама-Елга авылында урам утлары челтәрен норматив хәлгә китерүгә, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрүгә түләү өчен тоту?"

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыенын кибет янында түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Кама-Елга авылы, Кама-Елга урамы, 26А йорты.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Кама-Елга авылы территориясендә Кама-Елга урамы, 26А йортта урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Бишмунча авыл
җирлеге башлыгы Р.Г. Фазлыев